“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советы
КАРАРЫ

“7” март 2019 ел № 114

2017 елның 4 августындагы “Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советы депутаты статусы турында”гы Нигезләмәсе турында”гы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советының Карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга үзгәрешләр кертү сәбәпле, гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, “Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2017 елның 4 августындагы “Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советының 58 номерлы Карары белән расланган “Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
1.1. 11 маддәнең 1 өлешенең 1 пунктчасын “сәяси партия белән” сүзләреннән соң “билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюз” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- Кама Тамагы штп, Совет урамы, 11 йорт, җирле үзидарә бинасы;
- Кама Тамагы штп, К. Маркс урамы, 105 йорт, китапханә, уку залы,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Башлыгы вазыйфаларын башкаручы В. П. Сороковнин